ТИР БӘЯСЕ
Районнарда комбайнчыларга өстәмә кызыксындыру чаралары да каралган
> 2

РОБОТЛАР ДӘВАЛАР
Медицина белән IT-тармак бер-берсенә ничек бәйле?
> 3

ТАРИХ ЭЗЛӘРЕ
Казахстан галимнәре Татарстан архивларында кыйммәтле ядкәрләргә тап булган
> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм ата-аналар өчен махсус сәхифә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 125 (28898) | Шимбә | 27 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бәйрәм уңаеннан

Урам тулы халык, күңелләрдә – өмет, һәр тарафта – бәйрәм рухы. Кемнәрдер 30 августны шулай тасвирлый. Популяр җырчылар җитәкләгән гармунчылар парады, төрле фестивальләр, кичке концерт, чираттагы ял көне. Республика көнен әнә шулай күрүчеләр дә бар. Әлеге тарихи бәйрәмнең әһәмиятен, аның мәгънәсен онытып бетермәс өчен нәрсә эшләргә кирәк?

Журналист, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев фикеренчә, бүген безгә Татарстанны, федерализмны, Россия Федерациясе һәм Татарстан Конституциясендә язылган милли-мәдәни хокукларны якларга кирәк.

– Республика көне – безнең буын өчен дә, Татарстан һәм аның тарихы белән кызыксынган, милләт өчен борчылган башка бик күпләр өчен дә зур вакыйга. Декларация республиканың бүгенге уңышлары нигезендә ята. 1990 елның 30 августында Ирек мәйданы тулы халык иде. Бер елдан соң да бу көнне Болак буйлары, Ирек мәйданы, Кабан күле буе кеше белән тулды. Казанда гына да 400 мең кеше әлеге зур вакыйганы бәйрәм итәр өчен урамнарга чыкты. Менә шундый зур бәйрәм иде! – дип сөйләде ул. – Бүген халыкның республикага карата мөнәсәбәтен бу көннең әһәмиятен аңламау яки аңларга тырышмау гына билгеләми. Хәзер яңа буын үсте. Алар без белгән Татарстанны белмиләр. Хәзерге буын искиткеч алдынгы республикада яшәргә күнеккән. Ләкин без аларга Татарстанның сакларга кирәклеген аңлатырга тиеш. Чөнки хәзер федератив дәүләт төзелешен бөтен кеше дә яратмаска мөмкин. Унитар дәүләт төзергә кирәк, Россиядә бер генә милләт, бер генә дин булсын, диючеләр дә бар бит. Шуңа күрә хәзер Татарстанны, федерализмны, Россия Федерациясе һәм Татарстан Конституциясендә язылган милли-мәдәни хокукларны якларга кирәк дип саныйм. Демократик тормыш кануннар үтәлешенә, халык ихтыярына бәйле. Милли һәм сәяси битарафлык яшьләребезне имгәтмәсен иде.

Күңел ачу белән мавыгып, бу көннең мәгънәви ягын онытырга ярамый. Тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев әнә шундый фикердә.

– Республика көне – тарихи, татар халкы өчен бик әһәмиятле бәйрәм. Бу шулай булды һәм булачак та. Ләкин бәйрәмнәр күңел ачуга гына кайтып калырга тиеш түгел. Тарихи кыйммәте зур булган бәйрәм – биргәк тә. Бу көн – уйлану, үткән юлны барлау, нинди нәтиҗәләр ясау, үзебезнең бүгенге урыны билгеләү, киләчәкне фаразлау, җитди мәсьәләләр турында уртага салып сөйләшү өчен яхшы нигез. Һәм мондый бәйрәмнәр, һичшиксез, бик кирәк. Соңгы арада, күңел ачу белән мавыгып, бу турыда оныта башладык, – диде ул. – Бәйрәм элек ничек булган да, хәзер ничек, дип чагыштыру бик үк дөрес булмас. Чөнки 1990 нчы елларда халыкның кәефе башка, өметләре зурдан, офыклар да ачыграк кебек иде. Дөнья үзгәрә. Кызганыч, бар нәрсәне дә элеккечә калдырып булмый. Яңа сәяси шартларга һәм, гомумән, яңа тормышка яраклашырга гына кала. Билгеле, моны битарафлык белән бутарга ярамый. Әйткәнемчә, бәйрәм итүнең рәвеше үзгәрсә дә, мәгънәви ягы кимергә тиеш түгел.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КҮҢЕЛ АЧУ ГЫНА ТҮГЕЛ

Журналист Альберт Шакиров фикеренчә, безгә бу көннең эчтәлек-мәгънәсен ача торган сәнгать әсәрләре булдырырга кирәк.

– 30 августны Республика көне дип бәйрәм итүнәрен күптән инде ишеткән юк инде. Күпләр, биргәк тә яшь буын бу көнне күңел ачу чарасы буларак кабул итә. Гомумән, 16–17 яшьләр тирәсендәгеләр, ягъни безнең дәвамчыларыбызның фикерләвендә миллилек, татарлык сизелми. Белмим, бәлки алар кешенең аңында сонрак барлыкка киләдер, – диде ул. – Республика көненә үз статусын кире кайтару өчен хәйран гына тырышырга туры киләчәк. Аның мәгънәсен, әһәмиятен аңлатырга, сөйләргә кирәк. Әйтик, әлеге темага кагылышлы видеоэмалар эзли башлыйсың икән, 1990 нчы елларда төшерелгән кадрларны гына табып була. Безгә бу көннең эчтәлекмәгънәсен ача торган сәнгать әсәрләре булдырырга кирәк. Әйе, ул безнең тирән тарихыбыз түгел, яңа тарих. Ләкин ул да – тарих бит. Әлеге вакыйгалар тормышыбызда үз урынын табарга тиеш.

Блогер Ләйлә Леron да бу көн турында күбрәк аңлатырга, күбрәк сөйләргә кирәк дигән фикердә.

– 1985–1990 нчы елларда туган, шул чорда үскән яки республика өчен мөһим вакыйгаларның шаһиты булганнар әлеге бәйрәмнең әһәмиятен дә, мәгънәсен дә яхшы аңлый. Яшь буынга да бу хакта сөйләргә иде. Үз телләрендә, аңлаешлы, үтемле итеп. Чөнки алар бу көнне, беренчедән, Шәһәр көне дип атый. Икенчедән, күңел ачып, бушлай концерт карап кайту мөмкинлеге буларак кабул итә. Бәйрәм көнне дә республика тарихының бу битләре телгә алынмый икән, ул мәгълүматтан мәхрүм калган яшьләр бу көннең мәгънәсен ничек аңласын?

Гаилә эчендә битараф булмау шулай ук мөһим. КФУ студенты, Казан кызы Алинә Зарипова бу көнне кечкенәдән көтеп ала.

– Башкаларда ничектер, әмма безнең гаиләдә 30 август – чын бәйрәм. Әти-әнием өчен – биргәк тә. Бәйрәм рухын миңа да кечкенәдән үк сеңдерде алар. Казан урамнары буйлап җәяүләп йөрү, бәйрәм чараларына чыгу нинди дә кечкенә бер традициягә әйләнде. Үсә төшкәч, Республика көнен ни өчен нәкъ менә 30 августта билгеләп узуларын да сөйләделәр. Соңгы елларда бәйрәм көнне милли киемнәребезне киеп каршылау шулай ук матур гадәткә керде, – дип сөйләде Алинә.

Үсмәсә дә ярар иде

Казан яңа йортларда торак бәясе үсү буенча Россия шәһәрләре рейтингында беренче урынга чыккан. РБК хәбәр иткәнчә, быел гыйнвардан август аена кадәр Татарстан башкаласында бер квадрат метр торак мәйданы хакы 27 процентка артып, 179 мең сумга җиткән. Икенче урынга Ростов-Дон чыккан (үсеш – 26%, бер «квадрат» хакы – 118 мең сум). Самара – өченче (25%, 97,5 мең сум). Беренче биешлеккә шулай ук Чиләбе (21%, 83,3 мең сум) һәм Воронеж (18%, 95,4 мең сум) кергән. Шул ук вакытта Мәскәү рейтингта 16 шәһәр арасыннан 15 нче урынны алган: бирда бер квадрат метр бәясе ел башыннан 5 процентка (321,2 мең сум) үскән. Россия башкаласы фәкать Краснодарны (3%, 129,6 мең сум) гына артта калдырган.

Белгечләр торак бәясе буенча Казан һәм Ростов-Дон шәһәрләренең алда баруын ел башында яңа йортларда бәяләрнең чагыштырмача арзан булуына бәйләп аңлата. Ә Краснодарда, шулай ук Мәскәүдә, киресенчә, башта кыйммәт булган, аннан инде артык үсмәгән.

Җирнең кадерле чагы

Татарстанның ике шәһәре – Казан һәм Чаллыда күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлеге бирү авырлык белән бара. Сәбәбе – кытлык зур булу. Тагын 6 шәһәрдә кишәрлекләр бик аз санда. Болар – Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск, Яшел Үзән, Баулы һәм Бөгелмә.

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары Артур Галиев әйтүенчә, республикада 25866 күпбалалы гаилә җир көтә. Бөгелмә, Лениногорск, Әлмәт, Яшел Үзән, Кукмара, Баулы, Лаеш, Биектау, Арча һәм Түбән Кама районнарында җир кишәрлеге бирү планы 80 процента тулмаган. Балтач, Тукай, Зәй һәм Алексеевск районнарында – 80–90%. Шул ук вакытта 21 районда бу күрсәткеч 90нан 99 процентка кадәр җитә. Ә инде Әгерҗе, Аксубай, Мамадыш, Минзәлә, Нурлат, Балык Бистәсе, Спас районнары күпбалалы гаиләләрнең барысын да җир кишәрлеге белән тәэмин иткән.

Быел барлыгы 1733 кишәрлек бирелгән. Бүгенгә республикада нибары 4 мең кишәрлек запасы бар. Исемлеккә кертелгән гаиләләрнең ихтыяҗын каплау өчен бик аз бу. Татарстанда 69622 гаилә җир кишәрлеге бирү исемлегенә кертүне көтә. 43,7 меңнән артыгы (66%), ниһаять, җир алу бәхетенә ирешкән.

Урманче варислары

Быел Бакый Урманче премиясенә Әлфия Саргин, Диләрә Наурузова, Динар Сәлимов, Луиза Фәсхетдинова, Нина Горюнова лаек булды. Алар «Рәсем сәнгате», «Графика», «Сынлы сәнгать», «Декоратив-гамәли сәнгать», «Сәнгать теориясе һәм тарихы, тәнкыйть һәм сәнгать белеме» номинацияләрендә иң осталары булып танылды. Татарстанның Сынлы сәнгать өлкәсендәге абруйлы бүләген лауреатларга мәдәният министры Ирада Әюпова тапшырды.

Сүз уңаеннан, татар рәссамы, сынчы һәм педагогы Бакый Урманченең тууына быел 125 ел тулды. Аның исемендәге премия исә 2003 елдан бирле тапшырыла.

Хәтәрдән сакласын

Соңгы 7 айда Россия юлларында куркыныч очраклар кимегән. Шулай ук һәлак булучылар саны да 2,6 процентка азайган. Гыйнвар – июль айларында авариядәрдә 7146 кешенең гомере өзелгән. Белгечләр әйтүенчә, юл-транспорт һәлакәтләренең кимү төшүе «Юл хәрәкәте иминлеге» федераль проектын гамәлгә ашыруга бәйле.

Дәүләт автомобиль инспекциясендә билгеләп үтелгәнчә, ел башыннан бирле юлларда 84 мең кеше җәрәхәтләнгән-имгәнгән. Фаҗигаләрнең яртысы диярлек (45,1%) «корыч ат»ларның бәрелешүенә бәйле. Дүрттән бер өлеше чамасы (25,4%) җәяүлеләрне бәрдерүгә туры килә.

ЮХИДИ мәгълүматлары буенча, аварияләрнең күпчелеге машина йөртүчеләрнең юл хәрәкәте кагыйдәләрен санга сукмавы (юллар чатыннан дөрес узмау, җәяүлеләргә юл бирмәү, каршы як полосага чыгу) сәбәпле килеп чыккан.

Мәгариф

Үз кеше

КФУДА – ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Гадел һәм намуслы булырга сүз бирәм! КФУның яңа ректоры Ленар Сафин уку йортының киңәйтелгән гыйльми совет утырышында әнә шулай дип вәгъдә итте. Аны әлеге вазыйфага тәкъдим итү чарасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия фән һәм югары белем бирү министры Валерий Фальков катнашты.

– КФУ ректоры вазыйфасына кандидат сайлауда республика фикеренә колак салган өчен, Росия Хөкүмәтенә рәхмәтемне белдерәм. Ленар Сафин безнең университеты тәмамлаган. Ул үз юлын юридик факультетның гади мөгаллиме итеп башлап, соңгы елларда Татарстанның Федерация Советында вәкиле булды. Һәрвакыт университет өчен стратегик инициативалар һәм проектлар эшләүдә актив катнашты, – диде Рөстәм Миңнеханов әлеге утырышта.

Президент Казан федераль университетын илнең югары белем һәм фән үсеше флагманнарының, иң әре фәнни мәгариф үзәкләренең берсе дип атады. Уку йортының төрле федераль проектларда, грантларда актив катнашуын әйтте. КФУда 48 меңнән артык студент белем ала, шуларның 11 меңе – чит илдән. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, университет фән һәм технологияләрнең барлык тармакларын берләштерер торырга тиеш.

Валерий Фальков белдергәнчә, һәр зур югары уку йорты, ректор сайлаганда, бу вазыйфада үз студенты булуын тели. Бу унайдан Ленар Сафин Казан университетына яхшы таныш. Ул вузны 1993 елда тәмамлаган, аннан соң шунда белем биргән. Университет традицияләрен яхшы белә. Фальков аны тәбәк, федераль дәрәҗәдә дә эшләгән, эш рәвешен белгән һәм озак еллар мәгариф индустриясе белән бәйләнештә булган кеше дип бәяләде.

– Зур университет ректоры үзендә бик күп унай сыйфатларны тупларга, талантларны берләштерергә тиеш. Аннан яшьләр белән бер дулкында булу, укытучылар мәнфәгатьләрен яклау, бизнес һәм дәүләт хакимияте органнары вәкилләре белән аралаша белү сорала, – диде Мәскәү кунагы.

Министр фикеренчә, ректорның төп бурычларыннан берсе уй-фикерләрне эшкә әйләндерүдән гыйбарәт булачак. Моның өчен индустрия белән тыгызрак элемтәләр урнаштыру кирәк. Бүгенге шартларда алдынгы технологияләрнең иң дәрәҗәдә мөһим булганын әйтеп тә торасы юк.

Яңа ректор коллектив алдында җаваплылык тоюын, гадел һәм намуслы хезмәт итәчәген белдерде.

– Тарихи университетның җитәкләү – зур җаваплылык. Классик уку йортында көндәшлеккә сәләтле кадрлар әзерләүне дәвам иттерәчәкбез. Шул ук вакытта, мин укытучыларга, укытуга, тикшеренүләргә, фәнгә игътибарны юнәлтергә кирәк, дип саныйм, – диде Ленар Сафин.

Теманың дәвамы 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Россия Дәүләт Думасы Рәисе:

Кара исәп белән исәпләгәндә дә, безнең гражданнарның керүен чикләү нәтиҗәсендә Европа 21 млрд евро югалта. Илләр арасына тимер пәрдә корып, юләрлекләре һәм наданлыклары аркасында, алар үз-үзләрен җәзага тарталар. Дөньядагы халыкның 80 проценты Россиягә каршы санкцияләрне хупламый. Кунакка йөрер урын җитәрлек.

(«Телеграм-канал»ында әйткән фикере)

РОССИЯДӘ – МОШЕННИКЛЫК

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре ачыклаганча, Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге быел чактан гына мошенниклык корбаны булмый калган. 83 процент очракта кырыгалдарлар телефон аша ялганларга теләсә, һәр бишенче кеше шикле смс-хәбәрләр кабул иткән икән.

КЕМНӘР КҮБРӘК АЛДАНА?

90%	18–24 һәм 35–44 яшь арасындагы кешеләр
89%	интернеттан актив файдаланучылар
87%	ир-атлар

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Көтү таралганны көтеп...

Халык кем ул? Халык гавамнан (массалардан) нәрсәсе белән аерыла? Массаларга акыл иңсен, алар фикерле булсын өчен, нинди шартлар кирәк? Гражданлык җәмгыяте ил, дәүләтләрне гармониядә яшәтергә, ялгышлардан сакларга сәләтлеме?

Яшәешебезнең асылына кагылышлы бу сорауларга җавап бирү һич тә җиңел түгел. Аларга язучы Владимир Войнович куйган сорауны дә өстәсәң – бигрәк тә. «Үзләренең акылсыз юлбашчылары артыннан, аларның портретларын күтәреп, алар әйткән шигарьләрне кычкырып чапкан миллионнарны нинди сүз белән, кем дип атау дөрес?»

Язучы соравына бер сүз белән генә «көтү» дип җавап биреп буладыр. Нинди җәмгыятьтә яши, ничек яши – ул хакта уйламаган, гамьсез, идеология белән исертелгән массалар әле дә – шушы XXI гасырда да – беркая да китмәде. Алар кешелек җәмгыятенең гомуми үсеше дигәндә һаман да тормоз ролен үтәп килә кебек. Кемдер: «Иле, җитәкчеләре шундый булгач, халык нишли ала соң?» – дияр. Ни генә дисәләр дә, төп гаеп – барыбер халыкта. Һәр халык үз өстендәге хөкүмәткә, үз лидерларына лаек, дип тиккә генә әйтмиләр. Түзә, язмышы белән килешә икән, аңа рәхим-шәфкать күрсәтергә беркем дә атлыгып тормый.

«Үзләренең акылсыз юлбашчылары артыннан, аларның портретларын күтәреп, дуамал шигарьләр кычкырып чапкан миллионнар». Күз алдына СССР заманындагы бәйрәм демонстрацияләре, урамнарны тутырган колонналар, Политбюро әгъзаларының фотосурәтләрен тоткан, репродуктордан яңгыраган өндәү-шигарьләргә «ура» кычкырып җавап кайтарган халык килеп баса. Шулай ук «казарма»да асралган, стройга тезелгән кешеләр, Төньяк Корея ише тоталитар дәүләтләрдәге кыргый тәртипләр килә. Кылынган сәяси «җинаять», мәсәлән, партия линиясе белән килешмәгән өчен «Өч буынлы җәза» законы нигезендә Төньяк Кореяда кеше үзе генә түгел, балалары, хәтта ки кайчан да булса туачак оныклары да (!) җаваплы икән. Тик шундый шартларда да каршылыкка, баш имәүгә урын кала. Ул юл, ихтимал, бердәнбердер – гомерне куркыныч астына куеп булса да, илдән качу. Язуларынча, качучылар елдан-ел арта. Тик 26 миллионлы күпчелек, юлбашчыдан, идарәчеләрдән иңдерелгән канун, кагыйдәләргә буйсынып, җан асравын дәвам иттерә: яттан белгән вазыйфалар, белмәгән хокуклар, иҗтимагый-сәяси фикер дигәндә бер юнәлештә, кушылганча гына уйлау, фәкыйрьлектәге тигезлек.

Уйлау, дию бу очракта дөрес тә түгелдер. Бер акыллы зат әйтмешли, бар кеше дә бертөрле уйлаган җирдә беркем дә уйламый. Көтү уйлый белми, көтү инстинкты белән яши. Массалар – тулысы белән «көтүче» ихтыярында. Тыныч яшәгәндә, алар – эш аты, сугыш чыга калса – туп ите. Һәм бер Төньяк Кореяда гына түгел. Илнең рәсми исеме – Корея халык демократик республикасы. Әгәр дә кайсыдыр ил атамасында «халык» сүзе, «демократик» кәлимәсе бар икән, көт тә тор: ул ил күп очракларда авторитар йә тоталитар, андагы гавам ирексез, кеше хокуклары үтәлми, демократия исе килми дигән сүз...

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге гавамны «массалар» дип атап кына калмый, аның икенче төрле мәгънәсен дә китерә. Гавам – гыйлемсез, аңсыз халык, социаль-сәяси битараф кешеләр төркеме. Ягъни тамак кайгысыннан башканы белмәгән, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләренә башына чөй каксаң да төшенмәгән, печтеки генә дә аналитик акылы булмаган катлау. Пропаганда исерткән, «идеология» дигән гипноз миңгерәүләткән масса никадәр күп булса, тоталитар дәүләткә, аның идарәче элитасына шулкадәр яхшы. Сүзлекләр «халык» дип килеп чыгышы, мәдәнияте, тарихы уртак булган кешеләр төркемен атый. Ләкин халык булып саналу да сай мәдәниятлелектән, тарихка битарафлыктан, ирек-хокуклар җәһәтендәге наданлыктан аерылу түгел әле. «Көтү»дә тормас өчен, бәндә аңлы гражданин булып формалашырга тиеш. Войновичны янә дә искә алганда, аның әле: «Халык күпчелек очракларда аерым кешедән аңгырарак», – дигән фикере дә бар. Ягъни массаларны ниндидер томана идеягә ышандыру аерым кешене ышандыруга караганда күпкә җиңел. Чөнки көтүдәге җан иясе көтү инстинктына, көтүдәге гомуми аңга, ягъни аңсызлыкка буйсына...

Империячел үткәне яисә бүгенгесе күңелен җылыткан, бөеклек белән туенып яшәгән халыклар да гавам чутында. Андыйлар да артык тук тормышта, дөньяның артына тибеп яшәми. Тик ул кавем шундый: чалбары тишек, арты ялангач булса булсын, иле генә бөек саналсын. Башка халыклар ул яшәгән илдән куркып, калтырап торсын. Үтә дә сәер мантыйк һәм менталитет булса да, ул бар, ул яши, кайчакларда миллионнар аңын биләп тора. Андыйларның «исерүе» шул дәрәҗәдә: алар ул системаны чәчрәп чыгып аклый һәм яклый. Җәберне дә җәбер дип түгел, башкача кабул итә. Бу җәһәттән Пушкин прозасы искә төшә. Алпавыт Троекуровның атна саен ат абзарында сыртлары каезланган, кимсетелгән крепостнойлары: «Безнең хуҗа тирәяк алпавытлар арасында иң гаяре, иң тәкәсе, беркемгә дә баш бирми торганы», – дип сөйләнә-сөйләнә аның белән горурланалар. Андый күренешне – корбанның үзен җәберләүчегә мәхәббәтен психологиядә «стокгольм синдромы» дип тә атыйлар. Швед башкаласындагы банкны басканда алынган тотыкларның, коткарылганнан соң да җинаятьчене яклавы, полиция белән хезмәттәшлеккә бармавы сәбәпле, әйләнешкә кергән мазохизмга тартым сәер сыйфат һәм төшенчә ул.

«Көтү»гә, ул тудырган төрле «мазохизм», ура-патриотизмнарга альтернатива – әлбәттә, хәтсез дәүләтләрдә яшәп, үзен бар яктан да аклаган гражданлык җәмгыяте. Гражданлык җәмгыяте – көтү булудан туктау, үз язмышыңны үзең билгеләргә алыну, хакимияткә йогынтылылык, аны контрольдә тоту, аны халыкка хезмәт иттерү. Андый җәмгыять, әлбәттә, үзеннән-үзе яралмый, тиз барлыкка килми. Аның өчен хөрлеккә даими йөз тотып яшәү кирәк. Фикер төрлелеге, демократик институтлар ягына борылу кирәк. Көтү таралсын өчен, халыкның уянуы, айнуы, хакимияткә таләпле булуы мөһим. Гражданлык җәмгыяте ул – вертикаль азмасын өчен яралган горизонталь бәйләнешләр. Теге яки бу тармакта эшләүче эшче, хезмәткәрләрне берләштергән, теләсә нинди хакимият органы белән аяк терәп көрәшергә әзер бәйсез профсоюзлар. Үзләре теләп оешкан, яшь буын мәнфәгатьләрен актив яклаучы йогынтылы яшьләр союзлары, нәтиҗәле эш күрсәтүче, дәүләт вертикаленә катнашы булмаган җирле үзидарәләр, башкалар. Горизонталь бәйләнешләр халыкны уяу, аңлы, омтылышлы итә. Гражданлык җәмгыяте булганда чиновниклар да гел башка, алар халыктан файдалана, аның хисабына яши алмый, ә чып-чын халык ялчыларына әверелә.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ



tatarstan.ru

ГЫЙЛЕМЛЕ СӘФӘР

Кичә республиканың Казан, Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәттәге югары уку йортлары дәрәҗәле кунаклар кабул итте. Россия фән һәм югары белем бирү министры Валерий Фальков Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән КамАЗның фәнни-техник үзәген, Әлмәттәге Югары нефть мәктәбе кампусын, вузларны барып күрде.

Рөстәм Миңнеханов белән Валерий Фальков иң элек Чаллыда КамАЗда булдылар. Биредә алар кабина каркаслары заводы һәм автомобиль заводы эше белән таныштылар. Аерым алганда, аларга машина, кабиналар җитештергәндә кулланылган автоматлаштырылган системаны тәкъдим иттеләр. Миңнеханов белән Фальков каркаслар заводындагы логистика зонасын, эретеп ябыштыру цехы белән үлчәү лабораториясен дә карады. 2019 елда ачылган әлеге заводта елына 55 мең каркас җитештерелә.

Автомобиль заводы исә – КамАЗның иң зур заводы. 700 м озынлыктагы төп җыю конвейерында берьюлы 54 машина җыела. Уртача алганда, һәр 5–6 минут саен бу конвейердан яңа «тимер ат» чыга. Кунакларга электр белән эшләүче йөк автомобильләре, электробус, водород ягулык элементларында эшләүче техниканы күрсәттеләр.

Валерий Фальков заводтагы җитештерүне оештыру дәрәҗәсен югары бәяләде. «Бу машинаның кабинасында утырганда, оешманың нинди зур юл үтүе сизелә. Бөтенләй башка дәрәҗәдәге продукция тәкъдим ителгән. Без бүген бирегә КФУның Чаллы филиалында алдынгы инженер мәктәбе өчен җитештерүнең ничек оештырылуын карарга һәм бурычлар турында фикер алышырга килдек. Әлеге мәктәп университет өчен дә, КамАЗ өчен дә мөһим, чөнки аларның технологик бурычлары бар», – диде министр.

Рөстәм Миңнеханов белән Валерий Фальков КФУның Чаллыдагы филиалында эшләп килүче инженерлар мәктәбендә дә булды. Алар биредәге фәнни-тикшеренү лабораторияләре белән таныштылар. КамАЗ хезмәткәрләре ел саен әлеге мәктәптә 30 төрле программа буенча белемен күтәрә. КФУның Чаллыдагы филиалы күптән түгел «Кибер Авто Тех» инженерлар мәктәбен төзү һәм үстерү мөмкинлегенә ия булган. Ул университет белән «КамАЗ» оешмасы арасындагы хезмәттәшлек җепләрен тагын да ныгытыр, дип фаразлана.

Алдынгы инженерлар мәктәбе проектын тормышка ашыру кысасында өч ел эчендә «КамАЗ» оешмасына 132 инженер әзерләргә җыеналар. Моның өчен биредә 4 бакалавриат, 5 магистратура һәм 1 специалитет программасы булдырылачак. Моннан тыш инженерлар мәктәбендә 9 квалификация күтәрү һәм 4 яңадан укыту программасы да гамәлгә керәчәк. Аның нигезендә КамАЗның 360 инженеры белемен арттыра алачак.

Белем дигәннән, Рөстәм Миңнеханов белән Валерий Фальков Түбән Каманың химия-технология институтында да булды. Бүген ул Кама агломерациясенең нефть химиясе һәм нефть эшкәртү оешмаларына белгечләр әзерләүче төп югары уку йорты булып санала.

Казан дәүләт милли тикшеренү технология университеты ректоры вазыйфасын вакытлыча башкаручы Юрий Казаков сүзләренә караганда, химия һәм нефть химиясе оешмалары бүген кадрларга кытлык кичерә. «Шул ук вакытта югары уку йортын тәмамлаучыларның күбесе Түбән Камадан китә. Хәлне үзгәртү өчен, Түбән Каманың химия-технология институтының сәнәгать тармагы белән хезмәттәшлеген ныгытырга кирәк. Бүген бу хезмәттәшлек түбән дәрәҗәдә. Студентлар өчен заманча инфраструктура да булдырырга кирәк. Болар бар да студентларны җәлеп итәргә ярдәм итәчәк», – ди Казаков.

Ул Түбән Камадагы әлеге вузның фән-мәгариф кампусы проекты белән дә таныштырды. Ул берничә уку корпусы, заманча тулай тораклар, нефть инжинирингы һәм цифрлы компетенцияләр үзәген берләштергән кампус булдыруны күздә тота. Анда проектларны сынау мәйданчыгы булдыру да планлаштырыла.

– Түбән Каманы без нефть химиясе башкаласы дип саныйбыз. Биредә нефть химиясе, нефть эшкәртү, шин җитештерү, энергетика оешмалары тупланган, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты һәм илнең мәгариф министры электротехника, оешмаларны энергия белән тәэмин итү кафедрасы эшчәнлеге белән дә таныштылар. Моннан тыш аларга конструкция ешлыгын үзгәртүче югары вольтлы уникаль җиһаз урнашкан фәнни-белем бирү лабораториясе турында да сөйләделәр.

Рөстәм Миңнеханов белән Валерий Фальков Азнакай районында һәм Әлмәттә булдылар. Әлмәттә алар «Югары нефть мәктәбе»нең кампусын карады.

МӘСКӘҮГӘ – ҖЫР ҺӘМ СӘНГАТЬ БЕЛӘН

Татар киносы, мастер-класслар, сәнгать эшлеклеләре катнашында гала-концерт... 21–25 августта Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәре узды. Башкалада узган чарада Президент Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

– Сезнең һәрберегез – Татарстан тарафдары, республикадан чыккан кешеләр. Барыгызга да чын күңелдән рәхмәт белдерәбез. Барыгыз да Татарстан өчен җан атасыз. Һәр елны август аенда, Республика көне алдыннан, Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәрен уздырабыз. Минем Мәскәү Хөкүмәтенә, шәхсән башкала мэры Сергей Собянинга әлеге мөһим традициягә һәрвакыт ярдәм итүләре өчен рәхмәт белдерәсем килә, – диде Рөстәм Миңнеханов Мәскәүнең халыкара музыка йортында узган кичәдә.

Әлеге чарада Татарстанның дәүләт бүләкләрен дә тапшырдылар. Җырчы Радик Юльякшин, мәсәлән, «Татарстанның атказанган артисты» билгесенә, фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы Камилә Вәлиева исә Мәскәү мэры Сергей Собянинның Рәхмәт хатына ия булды.

Сергей Собянин үзе бу кичәгә килмәсә дә, аның сәлам хатын укыдылар. «Башкаланың иҗтимагый һәм мәдәни тормышындагы бу күркәм вакыйга Россия халыкларының гасырлык дуслыгын һәм Мәскәү белән Татарстан арасындагы тыгыз элемтәләрне ассызыклый. Мәскәүлеләр Татарстан сәнгать осталарының үзенчәлекле иҗатын яраталар һәм бәялиләр», – дигән Мәскәү мэры.

Татарстан Мәскәүдә, елдагыча, бай программа тәкъдим итте. Республиканың мәдәният көннәре кысасында биредә татар телендә нәфис фильмнар күрсәтелде. Аерым алганда, мәскәүлеләр тәүге мәртәбә «Ибн Фадлан» фильмын тамаша кыла алды. Россия дәүләт балалар китапханәсендә татар балалар әдәбияты көннәре кысасында экспозицияләр буенча экскурсияләр дә үткәрелде. Моннан тыш татар халкының бөек шагыйрьләре – Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салу, Татарстан шагыйрьләре һәм язучылары белән иҗади очрашулар да узды.

Лидер һәм пионер

«Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсенә – 60 ел. Бу уңайдан Әлмәтнең «Нефтьче» мәдәният сараенда зур тантана узды. Предприятие хезмәткәрләре һәм ветераннарын республика җитәкчелеге исеменнән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикләде.

Парламент башлыгы тантанада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның котлавын укыды. «Әлеге күренекле дата компания тарихындагы тагын бер әһәмиятле вакыйгага – 300 миллион тонна нефть чыгаруга туры килде, бу уңайдан да сезне котлыйм! Бик күркәм шушы сан артында гаять зур тәҗрибә, киңкырлы белем, ә иң мөһиме – нефть тармагын үстерү һәм республиканың икътисади мөмкинлекләрен ныгытуга үзләреннән лаеклы өлеш керткән берничә буын нефтьчеләрнең фидакарь, югары дәрәҗәдә профессиональ хезмәте ята. Идарәнең алга таба да элек-электән килгән традицияләргә тугры калачагына – кешеләр һәм экологияне кайгыртып, Татарстанның табигый байлыкларын сакчыл үзләштерәчәгенә ышанам», – диелгән Президент котлавында.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, «Елховнефть» – бүген «Татнефть» структурасында нефть чыгару буенча лидер, нефтьне калдыксыз эшкәртү проектларын тормышка ашыруда, алдынгы технологияләрне гамәлгә кертүдә пионер булып тора. Идарә республиканың нефть сәнәгатен торгызуда, Әлмәт шәһәре һәм районының социаль инфраструктурасын яңартуда зур роль уйнады.

«Бүген «Татнефть» һәм аның «Елховнефть» кебек подразделениеләре ярдәмендә Әлмәттә яшәүчеләрнең искитмәле мөмкинлекләргә ия булуы белән горурланабыз. Заманча балалар лагерьлары, ял базалары, кунакханә, ат спорты мәктәбе, чишмәләрне төзекләндерү һәм агач утырту – чын профессионаллар командасының гаять зур эш нәтиҗәсе бу», – диде парламент рәисе тантанада.

Ул шулай ук хатирәләре белән дә уртаклашып алды. «Һөнәрегезнең бөтен кыенлыкларын беләм, үзем дә шушы тармакта эшләдем, хезмәт юлын нефть-газ чыгару идарәләренең берсендә башлап җибәрдем. Тормыш сабакларына, эшкә җаваплы мөнәсәбәткә Әлмәттә «Татнефть» коллективында өйрәндем», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Фәрит Мөхәммәтшин, «Елховнефть»не булдыру тарихын искә төшереп, «кара алтын» чыгаруда идарәнең күренекле сәхифәләрен телгә алып үтте. Идарә инде эшли башлавының беренче елында ук 1,1 миллион тонна нефть чыгарган. Сигез елдан соң «кара алтын» табуның еллык күләме – 10 миллион тоннага, 1975–1977 елларда иң зур күрсәткечкә – 12,7 миллион тоннага җиткән. Тулаем 60 ел эчендә «Елховнефть» барлыгы 339 миллион тонна нефть чыгарган. «Искиткеч зур саннар бу. Республика икътисадында нефть-газ чыгару тармагы, бюджетка иң күп акча кертүче тармак буларак, төп урыннарның берсен биләп тора, – диде парламент башлыгы. – Нефтьчеләр һәрвакыт республиканы үстерүгә ярдәм итеп, яңа мөмкинлекләр тудырып килә».

Фәрит Мөхәммәтшин предприятие коллективына, ветераннар һәм хезмәт династияләренә рәхмәт сүзләре җиткерде.

ТИР БӘЯСЕ

УРАК ӨСТЕНДӘ КОМБАЙНЧЫЛАРНЫҢ КҮҢЕЛЕН КҮРЕРГӘ ТЫРЫШАЛАР

Игенченең авыр хезмәте лаеклы бәясен алырга тиеш. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та әледән-әле искәртеп килә. Районнарда һәм хуҗалыкларда җир кешесен ничек зурлыйлар? Без шул хакта белештек.

Билгеле булганча, районнарда һәр атна саен алдынгы комбайнчыларны акчалата бүләклиләр. Кайдадыр аның күләме 1–3 мең сум булса, кайдадыр 2–5 мең сум. Боларга өстәп, кайбер хуҗалыкларда, районнарда өстәмә кызыксындыру чаралары да каралган.

Әнә Чирмешән районында «Сөлчә» җәмгыяте уракта үзен иң алдынгы буларак күрсәткән комбайнчыны дүрт центнерлы, бүген чалырлык үгез белән бүләкләргә вәгъдә биргән. «Палессе»лар белән ярышырга кыен булганлыктан, «Дон» комбайнчылары арасында җиңүчегә 1,5 центнерлы үгез биреләчәк икән.

– Башкача булмый, туганым, – диде «Сөлчә» җәмгыяте җитәкчесе Хәмзә Хамматов. – Мин аларның хезмәтен беркемгә дә теләмим, чөнки игенченең нинди шартларда эшләгәнен үзем генә беләм. Бу эсседә көн буе кырда бит алар. Менә әле яннарында басып торам. Берсе ватылып кайткан. Төн буе комбайн янында булды. Әле дә муеннан майга батып, техникасын рәтли ул. Бөтен кешене икмәк белән туендырыр өчен тырыша. Чәчүен чәчәсең, аны җыеп аласы да бар бит әле. Барысы да – шул комбайнчы егетләрнең җилкәсендә. Үзем дә – яшьтән эшләп үскән кеше мин. Көтүче дә, мал табибы да, колхоз рәисе дә булдым. Барысын да бик яхшы аңлыйм.

Сан

Республика Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының оператив мәгълүматлары буенча, **967 мең** гектардан артык мәйданда **3 млн 700 мең** тоннага якын уңыш җыеп алынган.

Хәмзә Хамматов әйтүенчә, хуҗалыкның 3181 гектар җире бар. Кырларда дүрт комбайнчы эшли. Шуларның икесе – «Палессе» комбайны.

– Егетләр бик тырышлар. Барлык игенчеләр арасында алдынгы урынга чыкканы үзенә ошаган үгезне сайлап алачак, – диде ул. – Моннан тыш, комбайнчыларга – бишәр, аларның ярдәмчеләренә өчәр түк печән кайтардык. Хезмәт хакларына өстәп, егермешәр мең сум премия дә бирдем. Аннан соң күпме эшләүләренә карап, өстәмә акча да булачак. Моннан тыш, үзләре нинди культура тели, берәр бункер шуны бирәм.

Башка районнар да игенчеләрен булдыра алганча зурлый. Актаныш районында, мәсәлән, авыл хуҗалыгы предприятиесе җитәкчесе, галим-агроном Кәрам Гарипов премиясе бар. Әлеге премиягә ия булган алдынгылар саллы гына күләмдә акчалата бүләкләнә, диделәр безгә районның матбугат үзәгендә. Арча районында да урып-җыю нәтиҗәләре буенча алдынгы 20 комбайнчыга унар мең сум премия каралган.

Зәйдә җир кешеләренә аеруча зур хөрмәт күрсәтәләр. Язын алдынгы механизаторларны «Гранта» машинасы биреп куандырсалар, көзен кыр батырына зур күләмле премия бирмәкчеләр. Зәй районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Фәргать Камалиев әйтүенчә, өч ел рәттән, ел нәтиҗәләре буенча алдынгы комбайнчыларга зур күләмдә өстәмә акча бирелә.

– Узган ел без андый игенчеләргә 50, 70 һәм 100 мең сум премия бирдек. Быел, икътисади яктан авыррак булгач, премиянең суммасы кимеде. Шулай итеп, быел 4,5 мең тоннадан артык ашлык җыйган игенчене – 70 мең сум, 4–5,5 мең тоннага кадәр ашлык суктыручыны – 50 мең, 3,5–4 мең тоннага кадәр җыйган кешене 30 мең сум белән бүләклибез. Әлеге акча хезмәт хакына өстәп бирелә, – диде идарә башлыгы.

Бүгенгә районда 3 мең тоннадан артык ашлык җыеп алучылар бар икән инде. Язын исә кыр эшләрендә актив катнашып, зур тырышлык күрсәткәннәрне хөрмәтләгәннәр. 15 механизаторга 50шәр мең сум күләмендә премия биргәннәр. Ә иң алдынгы тракторчыга 1 млн сумлык машина эләккән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мондый бүләкләр игенчеләрнең үзләренә дә ошый, билгеле. Яңа Чишмә районында 40 ел комбайнда эшләп, алдынгы урыннарны бирмәгән Исхак Нәҗиповның саллы бүләкләрдән бәхете булган. Шушы еллар эчендә ул күп тапкыр акчалата премияләр дә, терлекләр дә, башка затлы бүләкләр дә алган. Ләкин шулай да иң истә калганы – «Шевроле Нива» машинасы, ди.

– Аны миңа район 2018 елда бүләк итте. Аңа кадәр дә, аннан соң да әллә никадәр бүләк алдым, ләкин иң кадерлесе шул машина булды. Игенченең тынгысыз хезмәтен зурлау дип кабул иттем мин аны. 60 яшемне тутыргач, комбайннан тракторга утырдым. Шуңа күрә быел алдынгы комбайнчыларга нәрсә вәгъдә итүләрен белмим. Игенче бүләк дип эшләмәсә дә, биргәч, барыбер рәхәт, горурлык инде ул, – диде Исхак Нәҗипов.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАЗАХЛАРНЫҢ КАЗАНГА СӘЯХӘТЕ

Тарих эзләреннән

Бу көннәрдә Татарстанның төрле оешмаларында урнашкан архивларда бер төркем казах галимнәре эшли. Алар нинди максат белән килгән? Инде саргаеп беткән, гасыр тузаннары сеңгән документлардан ни табарга телиләр? Шул хакта без төркем җитәкчесе, тарих фәннәре докторы, профессор, Казахстан Республикасының Милли кульъязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар үзәге фәнни киңәшчесе Гөлфирә ОТЕПОВА белән сөйләшәбез.

:: Гөлфирә Елубаевна, Татарстанга нинди җилләр ташлады?

– «Архив 2025» дәүләт программасы кысасында 2022 елның 15 августыннан 31енә кадәр Казахстан Республикасы Мәдәният һәм спорт министрлыгының «Милли кульъязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар үзәге» Татарстан архивларына, китапханәләргә, музейларга фәнни-тикшеренү экспедициясе оештырды.

:: Ни өчен нәкъ менә татар иленә юл алдыгыз?

– Программа нигезендә без башлап Мәскәүгә юл тоткан идек. Анда шактый гына кызыклы документларга тап булдык. Казах халкының тарихы бай, шул ук вакытта бик бәхәсле. Без белмәгән нәрсәләр күп әле. Тарих төрле чыганакларда – кульъязмаларда, китапларда, архивтагы документларда, истәлекләрдә, хатларда саклана. Аларның барысы да зур кыйммәткә ия. Максатыбыз да изге: без бу байлыкны эзләп табып, киләчәк буыннарга тапшырып калдырырга тиешбез. Ә ни өчен Татарстанга килдек дигәндә, казах һәм татар халыкларының мәдәни һәм тарихи элемтәләре бик нык. Безне X–XIII гасырлардан алып, Төрек каһанлыклары, Кимәк каһанлыгы, Алтын Урда, Ногай Урдасы, Казан ханлыгы чорлары берләштерә. Әйтергә кирәк, Россия империясе чорында да тыгыз булган бу элемтәләр. Мәгърифәтле татарлар дала якларында белем бирү-агарту эше белән шөгыльләнүче беренче миссионерлар булганнар. Гомумән, татар халкы казах ханнары белән мөнәсәбәтләрдә арадашчы ролен үтәгән. Еш кына катнаш никахлар да пәйда булган.

:: Бүген бу мөнәсәбәтләр нихәлдә?

– Казах һәм татар халыклары арасында мөнәсәбәтләр әйбәт. Бездә татар диаспорасы иң зурларыннан санала. Анда барлыгы 350 мең тирәсе кеше берләшкән. Казанда да милләтәшләребезнең шундый ук автоном оешма төзегәнен белеп, бик шатландык. Җитәкчесе Сәгыйть Джаксыбаев белән очрашырга да өлгердек инде. Ул безгә берничә китап, кульъязмалар бүләк итте. Казахстанда – татарлар, Татарстанда казахлар җирле халык белән бик дустанә, мәдәни яктан да, икътисад өлкәсендә дә ярдәмләшеп яши дигән фикердә калдык.

:: Санаулы көннәр тиз үтә. Кайларда булдыгыз?

– Санап та бетерерлек түгел. Безне Татарстан дәүләт архивында, Николай Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә, Милли китапханәдә, КФУның халыкара мөнәсәбәтләр институтында, Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтында, милли музейда бик дустанә каршы алдылар, һәрьяклап ярдәм иттеләр. Барысына да зур рәхмәтләребезне җиткерәбез.

:: Ниләр таптыгыз?

– Бик зур хәзинәләргә тап булдык. Татарстан дәүләт архивында ун фондны карарга өлгердек. Аерым алганда, бу – Казан рухи академиясе профессоры, миссионер Михаил Машанов, Император фәннәр академиясе әгъза-мөхбире, Казан укытучылар семинариясе директоры Николай Ильминский, Казан император университеты профессоры Николай Катанов, Казан университеты, Казан нәшрият эшләре буенча вакытлы комитет фондлары. Төрки телләре өйрәнүчеләрнең, этнографларның, галимнәрнең шәхси фондларында Көнчыгышка, кыргыз далаларына сәяхәтләре турында бик күп кульъязмалар бар.

Николай Лобачевский исемендәге фәнни китапханәдә дә бай әчтәлекле материаллар саклана. Без монда 44 битле дәфтәргә юлыктык. Анда XIX гасырда яшәгән кыргыз-кайсаклар турында язылган, бу язма махсус Екатерина IIгә бирер өчен билгеләнгән. Китапханәдә шулай ук 1602–1603 елларда Рәшидәд-динә Җәмигать тәварих тарафыннан фарсы теленнән татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләр бар. Билгесез авторның казах ханнары шәҗәрәсен күреп тә бик шатландык. Иосиф Готвальдның коллекциясеннән 1861 елгы дөнья картасы да моңа кадәр кулланышта булмаган. Әлеге галим фондында табылган Чыңгыз хан һәм Аксак Тимер турындагы кульъязма да бик кызыклы. Бу тарихи әзеләр Казан император университетында тәрбияләнүчеләр өчен язылган булган. Шулай ук Филипп Ефремовның «Кыргыз даласына, Бохарага, Хивага, Фарсыга, Тибетка һәм Һиндстанга сәяхәт» дип аталган китабына, Николай Рычковның «Кыргыз-кайсак даласына сәяхәт»енең көндәлек язмаларына, Абай әсәрләренә дә юлыктык. «Себергә статистик күзәтү» китабында да кыргызларның тормышы, гореф-гадәтләре, йолалары тасвирланган. Әйтергә кирәк, китапханәнең фонды искиткеч бай. Монда эшләргә дә эшләргә әле.

Татарстан Республикасы Милли музее да бик шатландырды. Анда без галим, тикшеренүче Җәвәт Алмазов фондын өйрәнә башладык. Ул бөтен тормышын сак-скиф язуын өйрәнүгә багышлаган. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 46 язмасына анализ ясаган. Бу поэма соңрак татар әдәбиятын формалаштыруда төп рольләрнең берсен уйнаган бит. Шулай ук башкорт, казах, үзбәк, төрекмән тарихына да кереп калган.

Гөлфирә Отепованың шәхси архивыннан

:: Сез озак еллар халкыгызның тарихи эзләрен барлыйсыз. Казахларның тормышы татарлар белән үрелеп барган. Димәк, Казахстандагы архивларда да татарлар турында мәгълүматлар бар дигән сүз. Алар белән кызыксынучылар булдымы?

– Мин бу очракта юк дип әйтә алам. Һәрхәлдә, хәтерләмим. Сүз дә юк, аерым кешеләр, аерым очраклар булгандыр. Ә менә делегация белән килеп, ярдәм сораучылар булмады. Алга таба фикерләр белән уртаклашып, бер-беребезгә булышып яшәргә иде исәп. Шул җәһәттән Казанда конференцияләр, «түгәрәк өстәл»ләр үткәрергә җыенабыз. Казан галимнәрен үзебезгә чакырабыз. Без ярдәм кулы сузарга һәрвакыт әзер.

:: Казан ошадымы?

– Шәһәр урамнары буйлап йөргәндә, гел әбием искә төшә. Буе бәләкәй булганга, без аны кечкенә әби дип йөртә идек. Сөйләве буенча, Казаннан иде ул. Казахстанда яшәүче бабама кияүгә чыккан. Бик сагынып, өзгәләнеп яшәде. Ниндидер туганнарына хатлар да язып карады. Илдар исемле иккен хәтерлим. Җавап ала алмады бугай. Әйе, әбиемнең яшьлек эзләре калган Казан бик ошады. Тарихлы, затлы, мәгърур шәһәр. Дәрес, күп йөрергә туры килмәде әле. Болгарга сәяхәт кылдык. Казанда Кремль, Кол Шәриф мәчете белән таныштык. Башка милләт, башка диндә яшәүчеләр белән дустанә яшәвегезгә сокландык. Бездә дә төрле милләт вәкилләре яши. Тик мәсьәләннар күбрәк булганга, һәр җирдә мәчетләр төзелгән, чиркәүләр бик сирәк. Шуңа күрә вазгыять сездәгегә караганда башкачарак. Көтмәгәндә-уйламаганда, экспедициябез байрәмгә – Республика, Шәһәр көннәренә туры килде. Эшләргә вакыт азрак кала дип, бер яктан кайгырган да булдык, әммә татар иленең чын йөзен күреп китү – безнең өчен зур куаныч.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

1734 елга кадәр казахлар үзләрен «казак» дип йөрткәннәр. XVIII гасырда Россия империясе чикләрен көнчыгышка таба җәелдерә һәм Урал белән Көньяк Себергә үтеп керә. Нәтиҗәдә бер проблемага килеп төртелә: Дон белән Кубаньда яшәүче казакларны ничек тә булса шул ук исем белән аталучы төрки халыклардан аерырга кирәк була. Шуңа күрә дә төрки казакларны «кыргыз-кайсак» дип атый башлыйлар дип фаразлыйлар. «Кайсак» – казак сүзенең бозып язылган формасы, дигән версия да бар. Соңрак бу этнонимнан «кайсак» сүзе бөтенләйгә төшеп кала, казахлар кыргызлар дип кенә йөртелә. Вакыты белән «кыргыз-калмык» термины да кулланалар. Шул ук вакытта 1897 елгы җан исәбе алу мәгълүматлары буенча, «кара кыргызлар» Фиргана өлкәсендә генә яшәп, аларның саны бары тик 201579 кеше була. «Казах» термины революциядән соң, 1925 елда гына кулланышка кертелә.

2022 – Цифрлаштыру елы

РОБОТЛАР ДӘВАЛАМЫЙ. ӘЛЕГӘ...

МЕДИЦИНА БЕЛӘН IT-ТАРМАК БЕР-БЕРСЕНӘ НИЧЕК БӘЙЛЕ?

Замана һәм медицина бер урында гына тормый. Тормышны җиңеләйтә, вакытны янга калдыра торган мөмкинлекләр сәламәтлек саклау тармагына да бик кирәк. Цифрлаштыру медицина өчен ни дәрәҗәдә мөһим? Сәламәтлек саклау өлкәсендә яңа технологияләр җәлеп ителәме?

Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Айрат ГАРИПОВ шул хакта сөйләде.

Цифрлаштыру һәм медицина: юл уртакмы?

Гомумән алганда, сәламәтлек саклау тармагын цифрлаштыру өлкәсендә бик күп эш башкарылды инде. Әммә ирешелгән нәтиҗәләрдә генә тукталу мөмкин түгел, тармак мөмкинлекләре дә, халык ихтыяҗы да арта гына бара.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына Юлламасында 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан итте. Бу, һичшиксез, «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты кысасында төбәктә «Татарстан электрон сәламәтлек саклау» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә сәламәтлек саклауның бердәм цифрлы юнәлешен булдыру» проектын гамәлгә ашыруга тулысынча бәйле.

Социологик тикшеренүләр дә, рәсми статистика да шуны әйтә: халыкка дәүләт органнары тарафыннан күрсәтелә торган иң кирәкле хезмәтләр медицина тармагына карый. Бу – табиб кабул итү, медицина ярдәмен алу.

Ун еллап инде республикада табибка язылуның электрон системасы эшли. Телемедицинадан файдаланабыз. «Табиб-табиб» рәвешендәге консультацияләрдән «виртуаль обход», «виртуаль консилиум» кебек төшенчәләр дә өстәлде. Татарстанның цифрлы үсешенә ярдәм күрсәтү ассоциациясе белән берлектә радиологик дата-үзәк (яңа структура республикадагы барлык кыйммәтле югары технологияле медицина җиһазларын үз идарәсенә алачак. – **Авт.**) булдырылачак. Медицина хезмәткәрләренең эш урынын автоматлаштыру эше дә дәвам итә. 2021 елда республиканың барлык фельдшер-акушерлык пунктлары заманча моноблоклар белән җиһазландырылды, интернет челтәренә тоташты. Хезмәткә яраксызлык кәгазен тутыру һәм медицина экспертизасына юнәлеш алуны электрон рәвештә башкару мөмкин. Барлык медицина оешмалары бухгалтерия эше, кадрларны исәптә тоту, хезмәт хакы түләү буенча берләштерелгән системага күчте.

Беренче нәтиҗәләр

«Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты кысасында Россия сәламәтлек саклау министрлыгы белән Дәүләт хезмәтләре бердәм порталында һәр кешенең шәхси кабинетын булдыру буенча килешү бар. Күрсәтелгән медицина ярдәме, рецептлар, табиб билгеләүләре, лаборатор анализ нәтиҗәләре шул шәхси сәхифәдә булырга тиеш. Шушы буенча кысасында Татарстан медицина тармагында мәгълүмати системаларны заманчалаштыруны башкара. Сырхау белән табибның читтән торып аралаша алуы, үзара бәйләнеше соңгы елларда аеруча актуаль бит.

Ярдәм сизелә

Цифрлаштыруның тәүге этабында табибларга тагын да күбрәк эшләргә туры килә әле. Ник дигәндә, мәгълүмати системалар эшенә төшенергә, цифрлаштыруга күнегергә дә кирәк бит.

Мисалга, республикада ашыгыч медицина ярдәме һәм һәлакәтләр медицинасы юнәлешләренә караган мөмкинлекләр белән идарә итүнең тәбәк автоматлаштырылган системасы булдырылды һәм гамәлгә кертелде. Әлеге система медицина хезмәткәрләренең эшен ачык итә, булган ресурсларны нәтиҗәле файдаланууда булыша. Программа ашыгыч ярдәм күрсәтү бүлекләренең барысында да эшли. Моннан тыш, ашыгыч ярдәм бригадалары планшетлар белән тәэмин ителгән. Бу бригаданың урынын һәм статусын контрольдә тотарга, чакырулар буенча мәгълүмат алмашырга мөмкинлек бирә.

Киләчәк

Якын киләчәктә яңа технологияләр җәлеп ителер дип өметләнәбез. Әйтик, пациентның электрон медицина картасын булдыру; вакытында ярдәм күрсәтә алу өчен тормышларына аеруча куркыныч янаган сырхаулар регистрын булдыру; табибларга диагноз кую, табиб карары чыгарда ярдәм итә торган системаны гамәлгә кертү.



minzdrav.tatarstan.ru

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Рухи-әхлакый хәзинәләрне саклау һәм үстерүгә, тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгытуга зур өлеш кертүе, актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы Татарстан Республикасы мөфтиенең социаль проектлар буенча киңәшчесе, «Ярдәм-Помощь» илкүләм хәйрия фонды Советы рәисе – администрация җитәкчесе **Баязитов** Илдар Рәфкать улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары **Саматов** Тимур Илгиз улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директорының китапханә-инновация эше буенча урынбасары **Афанасьева** Елена Владимировнага, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының авыларa китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 20 номерлы филиалы – Каенлы авылы китапханәсе мөдире **Гарипова** Флера Галимҗан кызына, «Мәдәният-ял итү үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры (Чистай шәһәре) **Гринина** Светлана Владимировнага, «Әлмәт туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Зәйдуллина** Винера Кыяметдин кызына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең хореография укытучысы **Зарифуллина** Миләүшә Насих кызына, «Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Карасева** Наталья Алексеевнага, «Техника йорты» муниципаль автоном мәдәният учреждениесенең түгәрәк җитәкчесе (Бөгелмә шәһәре) **Рыжова** Галина Алексеевнага, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Салих Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директорының укыту-тәрбия эше буенча урынбасары, фортепиано классы буенча укытучысы **Сәфәргалина** Зөлфия Габдулла кызына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе Бирдебәк авылы клубы мөдире **Толстова** Евдокия Григорьевнага, «Биектау үзәкләштерелгән система үзәк мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе әйдәүче белгече **Уткузова** Ризалә Фәлвәт кызына, Чаллы шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Хәмәдуллина** Ильмира Нәҗметдин кызына, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Хафизова** Гөлсинә Сәетҗан кызына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы урынбасары **Хөснуллина** Лузия Фәйзрахман кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«БӨРЕЛЕ» ябык акционерлык җәмгыятенең «Бөреле» бүлекчәсе идарәчесе (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Әхмәдуллин** Марат Әмир улына, «Государев Амбар» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының производство буенча урынбасары (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Бондаренко** Надежда Борисовнага, «Азык-төлек программасы агросәнәгать компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Тәкәнеш» бүлекчәсе идарәчесе **Гарипов** Искәндәр Хәкимулла улына, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары **Гарипов** Ленар Наил улына, «Август-Теләче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина-трактор станциясе мөдире (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Гыймадиев** Инсафетдин Кашафетдин улына, «Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлек азыгы буенча агрономы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Миннебаев** Фәнил Әмирҗан улына, «Үзәк фәнни-методика ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе Татарстан филиалы директоры урынбасары **Мөбарәков** Айтуган Ризван улына, «ӘНӘК» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Татарстан» бүлекчәсе бухгалтеры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Нуртдинова** Зөбәрҗәт Факил кызына, «Кама арьягы-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Нуретдинов** Рөстәм Тәлгать улына, «ЧИРМЕШӘН» авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы рәисе (Татарстан Республикасының Чирмешән районы) **Хәйрисламов** Әлфрит Хәнәфи улына, «Новая Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Хисамов** Илһам Ислам улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте электр энергиясе белән тәэмин итү идарәсенең электр җиһазларын төзекләндерү цехы башлыгы **Новик** Александр Борисовичка, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте II сәнәгать зонасы заводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү идарәсе олигомерлар һәм гликольләр заводы электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү цехының электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Орлов** Николай Степановичка, «Казан электр техникасы заводы» акционерлык җәмгыяте баш энергетигы бүлегенең баш энергетигы урынбасары **Скворцов** Вячеслав Юрьевичка, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте I сәнәгать зонасы заводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү идарәсе пластик заводы электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү цехы башлыгы урынбасары **Шакиров** Фәрит Габделхак улына **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест



Ә СИН БЕЛӘСЕҢМЕ?

Табигать, әйләнә-тирә дөньяны яраткан балалар бу сорауларга һичшиксез төгәл җавап бирәчәк!

1 «Сапротроф» дип нинди организмнарны атыйлар?
а) фотосинтезда катнашучы организмнар;
б) кислород бүлеп бирүче организмнар;
в) башка организмнар таркалу нәтиҗәсендә үзләренә туклыклы матдәләр таба торган организмнар.

2 Каргалар кешеләргә үпкәләргә дә мөмкин. Бу дөресме?
а) юк;
б) бу исбатланмаган;
в) әйе.

3 Сыер сөте нинди төстә?
а) ак;
б) соры;
в) төссез.

4 Дөньядагы иң кечкенә елан яшәгән утрау.
а) Мальдив утраулары;
б) Барбадос утравы;
в) Мадагаскар.

5 Фил баласының тугандагы авырлыгы.
а) 90–120 кг;
б) 70 кг;
в) 10 кг.

Җаваплар: 1) в; 2) в; 3) а; 4) б; 5) а.

КОМБАЙНЧЫ ЯРДӘМЧЕСЕ РАМАЗАН ГЫЙБАДУЛЛИН:

«АВЫЛДА КАЛЫРГА ТЕЛИМ»

Басу-кырларда олылар белән беррәттән эшләүче яшьләрне күрү сөендерә. Актаныш районында яшәүче Рамазан ГЫЙБАДУЛЛИН – әнә шундый яшь, уңган комбайнчы ярдәмчеләренең берсе. Җәйге каникулын туган ягы басуларында файдалы итеп уздыра ул. Киләчәктә туган җирендә төпләнеп калырга тели.

:: Игенче хезмәтенә кызыксыну кайдан барлыкка килде?
– Безнең гаиләдә комбайнчылар юк, үзем кызыксына башладым. Техникага мәхәббәт кечкенәдән бар инде ул. Минем кыр корабында йөреп карыйсым килде. Басу-кырларны да бик яратам, шулай комбайнчы ярдәмчесе булып эшләү теләге туды.

:: Комбайнчы ярдәмчесе булып кайчаннан эшли башладың?
– Узган ел эшли башладым, урып-җыю эшендә катнаштым. Арпа, бодай, борчак, солы җыйдык. Быел да урып-җыю яхшы бара, хәзер арпа урабыз. Тәҗрибәле комбайнчы Ленар абый Рәхимов белән «Ташкын» хуҗалыгында бергә эшлибез. Бу көннәрдә уңыш җыю өчен һава торышы да шатландыра. Эш көнебез иртәнге җидедә башлана һәм кичке тугыз, уннарга кадәр дәвам итә.

:: Комбайнчы ярдәмчесе вазыйфаларына нәрсәләр керә?
– Эше күп инде аның. Бергә эшли торган комбайнчыга барлык эштә булышырга кирәк: техниканы ремонтларга, майларга, радиаторга су салырга, тәрәзәләрне һәрчак сөртеп торырга, басуга чыккач, пакусларны рәтләргә һәм башкасы.

:: Урып-җыю чорын көтеп аласыңмы?
– Урак вакыты җиңел түгел, тик мин аны барыбер түземсезлек белән көтеп алам. Җир эшен, икмәк тәмен белеп эшләвемә шатмын. Комбайнчылар белән бергә-бергә эшләве дә күңелле.

КУНАГЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

- Рамазанга – 16 яшь.
- Актаныштагы технология техникумының беренче курсын тәмамлаган.
- «Ташкын» хуҗалыгында комбайнчы ярдәмчесе булып эшли.
- Оста игенче булырга хыяллана.

:: Бу эштә нәрсә күбрәк ошый сиңа?
– Барысы да ошый. Иң рәхәте – рульгә утыру.

:: Синеңчә, комбайнчы хезмәтендә иң мөһиме нәрсә?
– Иң мөһиме – теләк. Теләк булмаса, эшләп булмый. Шулай ук куелган максатларга ирешү һәм үз эшеңне ярату.

:: Киләчәккә нинди планнар?
– Укып бетереп, авылда калырга, туган җирдә хезмәт итәргә телим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Белеп тор!

Укырга вакыт!

Каникулны барыбыз да ярата. Әмма ул да бик тиз үтеп китә шул. Тиздән мәктәпкә барыр чак та җитә. Организмны иртән торуларга әзерли башларга кирәк, димәк. Ничекме? Өйрәтәбез!

1. Кинәт түгел, акрынлап. Каникулда йокы күп эләккәндер сиңа. Төнлә ятып, көндез торулар да берни булмагандыр. Хәзер инде йокы режимын да көйлисе булыр. Иң мөһиме – аны уку елы башланырга бер-ике көн кала башламаска. Иң яхшысы – хәзердән. Әйтик, гадәтләнгән вакыттан берничә минутка, аннан инде бер сәгатькә иртәрәк йокларга ята башлагыз.

2. Физик күнегүләр мөһим! Йоклар алдыннан физик күнегүләр ясау организмны ардыру, энергияне киметү өчен файдалы.

3. Гаджетларсыз төн. Йокларга ятканда телефон, ноутбук, планшет ише заман уенчыкларын калдырып торырга гадәтләнергә кирәк. Алар йокларга комачау да итә, сәламәтлек өчен дә зыянлы. Йокы урыны караңгы булырга тиеш.

4. Карап ашыйбыз. Йоклар алдыннан кәһвә, газлы, баллы сулар һәм авыр ризыклар эчмәскә-ашамаска кирәк. Иң яхшысы – җылы сөт йә бүлмә температурасындагы җылымса су.

5. Салмак көй. Ничек йоклап китәргә дип интексәң, салмак музыка кушарга мөмкин. Әкият, аудиокитаплар да ярдәмгә килер. Төп кагыйдә – алар куркыныч, ярсыта торган булмасын.

Безгә язалар

Балык Бистәсе районының Яншык авылы малайларына трактор руленә утырырга әле иртәрәк. Әмма дүрт тәгәрмәчле «тимер ат»ны алар биш бармаклары кебек беләләр. Чөнки бөтен уеннары шул тирәдә.

Башыңны эшләт



Ит сабыр, күрсәт чыдамлык

Хикәя

СӘЕР ЕЛМАЮ

Гүзәл ӘДҺӘМ

Язгы каникулда әни мине Казанга кунакка җибәрде. Күпмегә дисәң, төп-төгәл – бер атнага! Мондый бәхет теләсә кемгә тәтеми ул, малай! Әни сүзендә торды: «Чиркене «бишле»гә генә бетерсәң, атна буе рәхәтләнерсең Казанда!» – дигән иде.

Менә шулай! Мин – Казанда. Әни җибәргән акча да ярап куйды әле: курчак театрында, аквапаркта, бәлзәм сыннар музеенда булдым, «Казан Арена»да футбол карадым. Билгеле инде, үзем генә бармадым, институтта укый торган Алинә апа белән йөрдек.

Ә менә бүген мине бәхет басты: Казан буенча экскурсиягә берүзем чыгып киттем. Апамның ниндидер семинарга әзерләнәсе бар икән. Үзе әйткән була: «Их, сине шәһәр буйлап йөртә алмыйм инде!» – ди. Миңа нәрсә! Мин шатландым гына! Утыз тапкыр транспортта йөри торган (проездной) билетны кесәгә салгач, Алинә апаның кирәге дә калмады. Шул сәяхәт вакытында бик сәер бер елмаю белән очрашуымны сөйлим әле...

Ул көнне Казанны аркылыга да, буйга да айкадым, малай! Метроның бөтен тукталышын да карап чыктым, трамвай-автобусларның кайсына телим, шунда менәм дә утырам. Кулда – телефон. Рәхәтләндем кәртечкәгә төшереп: «ялт та йолт», «шарт та чорт».

Әй! Мин бит сезгә сәер елмаю турында сөйләмәкче идем лә. Менә шул. Тәрәзә буендагы йомшак урындыкка иркенләп кереп утырдым да «келтер-келтер» генә автобуста барам, тәрәзә аша Казанны күзлим. Бер тукталышта керде халык, ул керде халык! Миңа кызык булып китте, рәхәтләнеп шуларны күзәтә башладым.

Авыл белән шәһәр арасында аерма юк дигән булалар. Булмас! Болар кигән туфли белән безнең авыл урамына чыгып кара син. Хәзер чумасың! Кисәң дә, клуб каршындагы асфальтта йөрсәң генә инде. Язгы пычракта безнең «Жигули» да гаражда тора әнә. Әти: «Май бәйрәме җитмичә, юл төшмәс әле», – ди...

Ә-ә-әй! Тагын читкә киткәнмен! Сүзем «сәер елмаю» турында бит әле.

Вә-ә-әт! Автобуста кеше күп. Минем утыргыч янына бер апа килеп басты. Апа дигәч тә, карт инде ул. Минем әби сымактыр. Чәчләрен әллә ничек итеп, бөдрәләтеп, күпертеп өеп куйган, аягында – үкчәле туфли, үзе ялтыравыклы сумка аскан.

Менә шул апа миңа төбәлде дә әллә ничек сәер итеп елмайды. Мин дә аңа карап куйдым. Казан чәчтарашына кереп, «человек-паук»тай, чәч кистереп чыккан идем. Әллә шуны ошатты инде. Әйдә, карый бирсен!

Мин дә карыйм. «Мондый матур киемнәр кисә, минем әби дә алай ук карт күренмәс иде», – дип уйлыйм. Уйлап кына бетердем, автобусыбыз «дык» итте дә кисәк туктап калды. Теге апа әздән генә борыны белән идәнгә төртелмәде инде. «Пырх!» итеп көлеп җибәрүдән үземне көчкә тыеп калдым. «Үкчәле туфли кимәскә идең!» – дим эчтән генә. Әнә минем әби: җәен – кәлүш, кышын киез итек төшми аягыннан. Йөри рәхәтләнеп.

Минем утыргыч токычына ныграк ябышты теге. Ә үзе елмая! Чын менә – миңа караган да елмая. Каядыр күргәнем дә бар сымак тоела башлады. Чынлап та, таныш икән бит. Камал театры тукталышында төшеп калгач кына исемә төште. Артистка бит ул! Театрда уйный! Телевизордан әллә ничә тапкыр күргәнем бар иде. Әбиемнең әйткәне хәтергә төште: «Быел – аның юбилее! Алтмыш биш яшен тутырды!» – ди. Их! Өлгермәдем инде. Исәнләшкән булсам, туган көне белән котласам, шәп буласы икән. «Бигрәк культурный малай», – дип уйлаган булыр иде.

Төшәр алдыннан шул артистка, миңа карап, тагын бер тапкыр елмайды. Әллә нинди, сәер иде аның елмаюы. Нишләптер, кызганып елмая кебек тоелды миңа ул. Мине нигә кызганырга инде, я? Дүртенче сыйныфта укып йөргән тап-таза, сәламәт, үземә күрә шактый чибәр генә бер егет бит мин! Җитмәсә, отличник та!

Шулай да, бик сәер! Миңа карап, нигә елмайды икән ул?

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 325

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+